Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Иске Кәшер авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2022 елның 18нче ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Иске Кәшер авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авылы Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; көндезге бүлек студентлары; хәрби хезмәт һәм контракт буенча үтүче гражданнар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш , яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне ,Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу;
- светодиод яктырткычлар урнаштыру;
- янгын машинасына ягулык майлау материаллары алу;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту, җәйге вакытта үләннәрне чабу, грейдерлау,тэзеклэндеру буенча хезмәт күрсәтүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен түләү.);
-Иске Кэшер авылы Гагарин-Совет зиратлары коймасын янарту/ материал сатып алу, договор буенча тулэу), инвентарьлар алу
- «Сарман»район газетасына некрологларны биру

3. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Н. Дәүләтҗанов